**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“17” ноябрь 2023 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә ту Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Мәрҗән торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы 2024 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Мәрҗән авылы зиратын чистарту өчен чыгымнар тоту;
- Мәрҗән авылын чистарту,төзекләндерү өчен чыгымнар тоту;
- Мәрҗән авылындагы уен майданчыгы өчен өстәмә койма кую.
- Мәрҗән авылы асфальт юлларында чокырларны ремонтлау. (эш һәм хезмәт өчен түләү);
- Мәрҗән авылында (М.Җәлил урамына) юл салу өчен вак таш сатып алу(эш һәм хезмәт өчен түләү);

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Мәрҗән авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Комыргуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Низамиев Ф.Ф.

СОВЕТ КОМЫРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КОМЫРГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИНН 1610000732